КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 12 апрель г.Казань № 235

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 17 февраль, 92 нче; 2014 ел, 31 май, 371 нче; 2014 ел, 5 сентябрь, 643 нче; 2014 ел, 1 декабрь, 936 нчы; 2015 ел, 26 март, 186 нчы; 2015 ел, 28 август, 626 нчы; 2015 ел, 25 сентябрь, 710 нчы; 2015 ел, 29 декабрь, 1000 нче; 2016 ел, 24 март, 160 нчы; 2016 ел, 13 август, 554 нче; 2016 ел, 6 декабрь, 898 нче; 2017 ел, 13 март, 134 нче; 2017 ел, 13 июль, 479 нчы; 2017 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2017 ел, 7 декабрь, 943 нче; 2018 ел, 24 гыйнвар, 35 нче; 2018 ел, 26 февраль, 107 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="10">«Еллар һәм чыга-наклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре</td><td colspan="3">Программаны финанслауның гомуми күләме – 10 039 610,28 мең сум тәшкил итә, шул исәптән җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 5 039 448,80 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 5 000 161,48 мең сум.<br>(мең сум)</td></tr>
<tr><td>Ел</td><td>Җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы</td><td>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</td></tr>
<tr><td>2014</td><td>957 036,6</td><td>668 907,79</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>771 639,0</td><td>631 712,01</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>742 042,5</td><td>683 366,98</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>609 879,1</td><td>721 262,7</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>641 787,5</td><td>755 291,9</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>653 706,3</td><td>761 994,6</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>663 357,8</td><td>777 625,5</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>5 039 448,8</td><td>5 000 161,48»;</td></tr>
</table>

Программаның III бүлегендә:

икенче абзацта «10 031 283,48» саннарын «10 039 610,28» саннарына алыштырырга;

дүртенче абзацта «4 991 834,68» саннарын «5 000 161,48» саннарына алыштырырга;

Программага теркәлгән 2 нче кушымтаның 7 графасында «1 374 122,6», «732 335,1», «1 388 752,6», «746 965,1» саннарын тиешенчә «1 382 449,4», «740 661,9», «1 397 079,4», «755 291,9» саннарына алыштырырга;

«2014 – 2020 елларга халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү чараларын тормышка ашыру һәм хезмәт миграциясен җайга салу. Эшкә урнашканда яшь инвалидларны озатып йөрү» ярдәмче программасында (алга таба – Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программа):

Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="2">«Еллар һәм чыга-наклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре</td><td colspan="4">Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 9 936 465,28 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 5 039 448,8 мең сум; Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 4 897 016,48 мең сум, шулардан инвалидларны (яшь инвалидларны да кертеп) эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтүгә һәм эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәткәндә озатып йөрүне оештыруга – 125,30 мең сум.<br>(мең сум)</td></tr>
<tr><td>Ел</td><td>Гомуми акча күләме</td><td>Җәлеп итәргә планлашты-рыла торган</td><td>Татарстан Республикасы бюджеты</td></tr>
</table>

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | федераль бюджет акчасы | акчасы |
| | 2014 | 1 611 314,39 | 957 036,60 | 654 277,79 |
| | 2015 | 1 388 721,01 | 771 639,00 | 617 082,01 |
| | 2016 | 1 410 779,48 | 742 042,50 | 668 736,98 |
| | 2017 | 1 315 776,80 | 609 879,10 | 705 897,70 |
| | 2018 | 1 382 449,4 | 641 787,50 | 740 661,9 |
| | 2019 | 1 401 070,90 | 653 706,30 | 747 364,60 |
| | 2020 | 1 426 353,30 | 663 357,80 | 762 995,50 |
| | Барлыгы | 9 936 465,28 | 5 039 448,80 | 4 897 016,48»; |

«Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелгән соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелгән соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикатор-лары) һәм аның бюджет нәтиҗә-лелеген бәяләү күрсәткечләре | Эш белән тәэмин итү программасын тормышка ашыру йомгаклары буенча 2020 елга түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү көтелә:<br>теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе 0,9 проценттан артып китүне булдырмау;<br>халыкны эш белән тәэмин итү дәрәҗәсен кимендә 65 процент тәэмин итү;<br>эшсезлекнең уртача дәвамлылыгын 2020 ел ахырына 5 айга кадәр киметү;<br>эшсез булып теркәлгән гражданнар санының кимендә 12 процентының һөнәри дәрәҗәсен күтәрүне тәэмин итү;<br>эш эзләү максатларында эш бнелән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән гражданнар санына карата кимендә 60 процент һөнәри ориентацияне оештыру;<br>эшсез булып теркәлгән гражданнарның уртача еллык санының кимендә 70 процентын иҗтимагый һәм вакытлыча эшләрдә мәшгульлеген тәэмин итү;<br>республикада яшәүче 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнар арасыннан кимендә 15 процентын укудан тыш вакытта эш белән тәэмин итүне тәэмин итү;<br>Ярдәмче программа гамәлдә булу чорында эшсез инвалидлар, күп балалы ата-аналар һәм инвалид балаларны тәрбияләүче ата-аналар өчен махсуслашкан эш урыннары булдыру;<br>эшкә урнашу өчен эшсез гражданнарга башка урынга күчкәндә, эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченгәндә булышлык күрсәтү – хезмәт базарындагы эшсез булып теркәлгән гражданнарның гомуми санында киеренкелек кимендә 1 процент булганда теркәлгән эшсез гражданнар санынннан кимендә 0,3 процент (киеренкелек 1 гә тигез яки артык |

| | |
|---|---|
| | булганда 0,5 процент);<br>кимендә 4,5 мең эшсез гражданны кече эшмәкәрлек тармагына җәлеп итү;<br>Татарстан Республикасының икътисадый актив халкының кимендә 90 процентына хезмәт базарындагы хәл турнида мәгълүмат бирергә;<br>700 меңнән артык гражданны эшкә урнаштыруга булышлык күрсәтү;<br>югары белем бирүче мәгариф программалары буенча белем алганнан соң өч ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен кимендә 55 процент тәэмин итү;<br>урта һөнәри белем бирүче мәгариф программалары буенча белем алганнан соң өч ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен кимендә 40 процент тәэмин итү;<br>югары белем бирүче мәгариф программалары буенча белем алганнан соң алты ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен кимендә 65 процент тәэмин итү;<br>урта һөнәри белем бирүче мәгариф программалары буенча белем алганнан соң алты ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен кимендә 50 процент тәэмин итү;<br>югары белем бирүче мәгариф программалары буенча белем алганнан соң алты ай узганнан соң һәм күбрәк вакыт эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен кимендә 15 процент тәэмин итү;<br>урта һөнәри белем бирүче мәгариф программалары буенча белем алганнан соң алты ай узганнан соң һәм күбрәк вакыт эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен кимендә 10 процент тәэмин итү;<br>һөнәри уку узганнан соң өч ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен кимендә 20 процент тәэмин итү;<br>һөнәри уку узганнан соң алты ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен кимендә 35 процент тәэмин итү;<br>һөнәри уку узганнан соң алты ай узганнан соң һәм күбрәк вакыт эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен кимендә 15 процент тәэмин итү;<br>өстәмә һөнәри программаларны (квалификация күтәрү программалары һәм һөнәри яңадан әзерләү программалары) үзләштергәннән соң өч ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен кимендә 35 процент тәэмин итү;<br>өстәмә һөнәри программаларны (квалификация күтәрү программалары һәм һөнәри яңадан әзерләү программалары) үзләштергәннән соң алты ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен кимендә 50 процент тәэмин итү;<br>югары белем алганнан соң укуын дәвам иткән яшь инвалидлар арасыннан укып бетерүчеләр өлешен кимендә |

| | |
|---|---|
| | 0,5 процент тәэмин итү;<br>урта һөнәри белем алганнан соң укуын дәвам иткән яшь инвалидлар арасыннан укып бетерүчеләр өлешен кимендә 15 процент тәэмин итү;<br>халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендәге чаралар кысаларында укыган хезмәткәрләр арасыннан эшкә урнашкан хезмәткәрләр өлешен кимендә 90 процент тәэмин итү.»; |

Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программаның II бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Эш белән тәэмин итү ярдәмче программасын тормышка ашыру өлкәсендә дәүләт сәясәте өстенлекләре һәм аның максатлары, бурычлары, тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен тормышка ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 ел, 17 ноябрь, 1662-б номерлы карары белән расланган 2020 елга кадәрге чорга Россия Федерациясен озак вакытлы социаль-икътисадый үстерү концепциясе нигезендә эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп өстенлекләре түбәндәгеләр:

яшь белгечләрнең оешмаларда стажировкалары гамәлен киңәйтү, киләчәктә даими эш урынына урнашу максаты белән;

балаигъ булмаган балалары һәм инвалид балалары булган хатын-кызларны эш белән тәэмин итүне стимуллаштыру;

физик мөмкинлекләре чикләнгән затларны хезмәт эшчәнлегенә интеграцияләү өчен шартлар тудыру, аерым алганда инвалидлар өчен махсус эш урыннары булдыру, инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтүдә озатып йөрүне оештыру юлы белән;

халыкка һөнәри юнәлеш бирү һәм психологик ярдәм күрсәтү системасын, шул исәптән мәктәп укучыларының һөнәри ориентациясен үстерү, хезмәт базарында ихтыяҗ булган һөнәрләр, белгечлекләр буенча аларның хезмәт эшчәнлегенә мотивациясен күтәрү;

халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә яңа мәгълүмати мөмкинлекләрдән файдалану һәм мәгълүмат ресурсларыннан һәркем файдалана алырлык булуны тәэмин итү;

эчке хезмәт миграциясенә ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.

Дәүләт сәясәтенең күрсәтелгән өстенлекләреннән чыгып Эш белән тәэмин итү ярдәмче программасы формалашкан, халыкны эш белән тәэмин итү, шул исәптән инвалидларны хезмәт эшчәнлегенә җәлеп итү юлы белән, һәм Татарстан Республикасы икътисады өчен кадрлар потенциалын үстерү аның максатлары булып тора

Әлеге максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү сорала:

1. Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфатын һәм һәркем алырлык булуын арттыру.

2. Эш эзләүче гражданнарны эшкә урнаштыруга булышлык күрсәтүнең нәтиҗәлелеген күтәрү.

3. Гамәлдәге эш урыннарын саклауга һәм яңаларын булдыруга булышлык күрсәтү.

4. Эш бирүчеләрнең кадрлар белән тәэмин ителеш ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерү.

5. Эшсез гражданнарга социаль ярдәм чараларын тормышка ашыру.

6. Инвалидларны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү. Инвалидларны эш белән тәэмин итүне озата баруны оештыру.

7. «Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү һәм эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү».

Беренче бурычны тормышка ашыру кысаларында түбәндәге төп чаралар карала:

хезмәт базарындагы хәл турында, шул исәптән социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен норматив-хокукый җайга салу, һөнәр-квалификация күзлегеннән чыгып эшче көчкә сорау һәм тәкъдим, һөнәри квалификация, әзерлек, яңадан әзерләү дәрәҗәләрен исәпкә алып, хезмәт күрсәтүләргә ихтыяҗ турында, шулай ук гражданнарны җитештерү, эшче көчне территорияләр ара һәм тармак ара яңадан бүлү һәм чит ил хезмәткәрләреннән файдалану процессына җәлеп итү, халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт хезмәте органнары һәм учреждениеләре тормышка ашыра торган чараларны массакүләм мәгълүмат чаралары аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, радио- һәм телевизион тапшыруларны, периодик басмаларны да кертеп, мәгълүмат белән тәэмин итү;

эш белән тәэмин итү, хезмәт мөнәсәбәтләре мәсьәләләре буенча мәгълүмат-белешмә материаллар, норматив документлар җыентыклары әзерләү һәм бастырып чышару (тиражлау);

предприятие (оешма) хезмәткәрләре санын яки штатын киметү яисә предприятиене (оешманы) бетерү планлаштырыла торган предприятиеләрдә (оешмаларда) махсуслаштырылган консультация пунктлары оештыру;

халыкны эш белән тәэмин итү тармагында халыкны эш белән тәэмин итүнең мобиль офисларыннан файдаланып дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

хәрби хезмәттән азат ителгән гражданнарның һәм аларның гаилә әгъзаларының, заманча шартларда хәрби хезмәт ветераннарының социаль-икътисадый һәм хокукый хәлен, матди хәле һәм хокукый якланганлык дәрәҗәсен тикшерү оештыру;

республиканың хезмәт базары торышын алга китеп фаразлау максатында республиканың хезмәт ресурслары базарын тикшерү һәм анализлау һ.б.

Икенче бурычны тормышка ашыру кысаларында түбәндәге төп чаралар каралган:

матди ярдәм күрсәтеп, эш эзләүдә авырлыклар кичерүче эшсез гражданнар, 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге урта һөнәр белемле һәм беренче тапкыр эш эзләүче эшсез гражданнар, гомуми белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан беренче тапкыр эш эзләүче эшсез гражданнар өчен түләүле җәмәгать эшләрен үткәрүне, аларны вакытлыча эшкә

урнаштыруны оештыру; матди ярдәм күрсәтеп, 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру.

Өченче бурычны тормышка ашыру кысаларында түбәндәге төп чаралар каралган:

эшсез гражданнарның үзмәшгульлегенә ярдәм күрсәтү, оештыру-консультация хезмәтләре күрсәтүне, эшмәкәрлек эшчәнлеген дәүләт теркәвенә алганда гражданнарга бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне, шулай ук тиешле дәүләт теркәве өчен документлар әзерләүдә бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне кертеп;

һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче оешмаларны тәмамлаучылар һәм иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәү учреждениеләреннән азат ителгән эшкә урнашкан затлар арасыннан (шул исәптән резервлана торган эш урыннарына) эшсез гражданнарны халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре юлламасы буенча вакытлыча эшкә урнаштырылганнар хезмәте өчен өчен түләү буенча эш бирүчеләрнең чыгымнарын компенсацияләү.

Дүртенче бурычны тормышка ашыру кысаларында түбәндәге төп чаралар каралган:

инвестиция проектлары нигезендә эшчәнлекне реструктуризацияләү һәм модернизацияләүне тормышка ашыручы оешмалар хезмәткәрләрен алга китеп һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру;

өч яшькә кадәр бала тәрбияләү буенча ялда булган, хезмәт эшчәнлегенә әйләнеп кайтырга планлаштырган хатын-кызларны һөнәри укытуны һәм өстәмә йөнәри укытуны оештыру;

яшьләр һәм студентларның хезмәт отрядларында катнашучыларны эшче һөнәрләре буенча һөнәри әзерләү;

Татарстан Республикасында яшәүче пенсионерлар, пенсия алды һәм өлкән яшьтәге гражданнарга компьютер грамотасы нигезләрен укыту буенча «Интернет-Озак яшәү» проектын тормышка ашыру;

конкурентлылык сәләтен күтәрү, киләчәктә эшкә урнашу, үзмәшгульлек һәм эшмәкәрлек максатларында эшсез гражданнарны һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри укыту буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүне оештыру, шулай ук конкурентлылык сәләтен күтәрү һәм киләчәктә эшкә урнашу максатларында теркәлгән, шул исәптән армиядә чакыру буенча хезмәт иткән, хәрби хезмәттән азат ителгән гражданнарны һәм аларның үзмәшгульлеккә, эшмәкәрлеккә һәм кече бизнеска йөз тоткан гаилә әгъзаларын, чакыру яшендәге затларны хәрби-исәп белгечлекләре буенча, шулай ук туры килә торган эш эзләү максаты белән теркәлгән гражданнарны һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү;

эшчәнлек (һөнәр) тармагын сайлау, эшкә урнашу, һөнәри уку үтү һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында гражданнарның, шул исәптән белем бирү оешмалары укучыларының һөнәри күзаллауын оештыру;

хезмәт базарында социаль яраклашу буенча дәүләт хезмәте һәм эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү, социаль яраклашу һәм эшкә урнашканда озата бару буенча комплекслы хезмәт күрсәтү.

Бишенче бурычны тормышка ашыру кысаларында түбәндәге төп чаралар каралган:

эшсезлек буенча пособиене үз вакытында түләү һәм матди ярдәм күрсәтү юлы белән эшсез гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүне тәэмин итү;

билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга түләүләрне гамәлгә ашыру (эш белән тәэмин итү органнары җибәрүе буенча һөнәри уку һәм өстәмә белем алу чорында степендия һәм эш белән тәэмин итү органнары җибәрүе буенча һөнәри уку һәм өстәмә белем алу чорында матди ярдәм түләү өлешендә);

эшсез гражданнар арасыннан затларга вакытыннан алда рәсмиләштерелгән пенсияләр түләү буенча чыгымнарны Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенә кайтару.

Алтынчы бурычны тормышка ашыру кысаларында түбәндәге төп чаралар каралган:

квота кысаларында инвалидлар өчен махсус эш урыннары булдыруга эш бирүчеләрнең чыгымнарын компенсацияләү;

инвалидларның иҗтимагый оешмалары тарафыннан оештырылган предприятеләрдә инвалидларның эш урыннарын саклауга субсидияләр бирү;

инвалидлар өчен булдырылган (җиһазландырылган) эш урыннарына эшләмәүче инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтүне оештыру;

эшсез инвалидларның үзмәшгульлегенә булышлык күрсәтү, оештыру-консультация хезмәтләре күрсәтүне, эшмәкәрлек эшчәнлеген дәүләт теркәвенә алганда гражданнарга бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне, шулай ук тиешле дәүләт теркәве өчен документлар әзерләүдә бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне кертеп;

эшсез инвалидларга һөнәри укытуны һәм өстәмә һөнәри белем бирүне, һөнәри юнәлеш алуны, хезмәт базарында социаль яраклашуны һәм психологик ярдәм күрсәтүне һ.б. оештыру.

Җиденче бурычны тормышка ашыру кысаларында түбәндәге төп чаралар каралган:

оешмаларның эштән чыгару янаган яки эштән чыгарылган, хезмәткәрләр санын яки штатын киметү яисә бетерү белән бәйле бүтән ошемалардан алынган хезмәткәрләрне алга китеп һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү, шул исәптән Татарстан Республикасыннан читтә, шулай ук хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү программасын тормышка ашыру белән бәйле эш белән тәэмин итүнең нәтиҗәлелеген күтәрү чараларында катнашучы хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү;

эштән чыгару куркынычында булган, шулай ук хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү программасын тормышка ашыру белән бәйле һәм эш белән тәэмин итүнең нәтиҗәлелеген күтәрү буенча чараларда катнашучыларны эштән аза иткәннән соң бүтән оешмалардан кабул ителгән хезмәткәрләр хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны өлешчә каплау.

Эш белән тәэмин итү ярдәмче программасын тормышка ашыру йомгаклары буенча 2020 ел ахырына түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү көтелә:

теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе 0,9 проценттан артып китүне булдырмау;

халыкны эш белән тәэмин итү дәрәҗәсен кимендә 65 процент тәэмин итү;

эшсезлекнең уртача дәвамлылыгын 2020 ел ахырына 5 айга кадәр киметү;

эшсез булып теркәлгән гражданнар санының кимендә 12 процентының һөнәри дәрәҗәсен күтәрүне тәэмин итү;

эш эзләү максатларында эш бнелән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән гражданнар санына карата кимендә 60 процент һөнәри ориентацияне оештыру;

эшсез булып теркәлгән гражданнарның уртача еллык санының кимендә 70 процентын иҗтимагый һәм вакытлыча эшләрдә мәшгульлеген тәэмин итү;

республикада яшәүче 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнар арасыннан кимендә 15 процентын укудан тыш вакытта эш белән тәэмин итүне тәэмин итү;

Ярдәмче программа гамәлдә булу чорында эшсез инвалидлар, күп балалы ата-аналар һәм инвалид балаларны тәрбияләүче ата-аналар өчен махсуслашкан эш урыннары булдыру;

эшкә урнашу өчен эшсез гражданнарга башка урынга күчкәндә, эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченгәндә булышлык күрсәтү – хезмәт базарындагы эшсез булып теркәлгән гражданнарның гомуми санында киеренкелек кимендә 1 процент булганда теркәлгән эшсез гражданнар саныннан кимендә 0,3 процент (киеренкелек 1 гә тигез яки артык булганда 0,5 процент);

кимендә 4,5 мең эшсез гражданны кече эшмәкәрлек тармагына җәлеп итү;

Татарстан Республикасының икътисадый актив халкының кимендә 90 процентына хезмәт базарындагы хәл турнында мәгълүмат бирергә;

700 меңнән артык гражданны эшкә урнаштыруга булышлык күрсәтү;

югары белем бирүче мәгариф программалары буенча белем алганнан соң өч ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен кимендә 55 процент тәэмин итү;

урта һөнәри белем бирүче мәгариф программалары буенча белем алганнан соң өч ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен кимендә 40 процент тәэмин итү;

югары белем бирүче мәгариф программалары буенча белем алганнан соң алты ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен кимендә 65 процент тәэмин итү;

урта һөнәри белем бирүче мәгариф программалары буенча белем алганнан соң алты ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен кимендә 50 процент тәэмин итү;

югары белем бирүче мәгариф программалары буенча белем алганнан соң алты ай узганнан соң һәм күбрәк вакыт эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен кимендә 15 процент тәэмин итү;

урта һөнәри белем бирүче мәгариф программалары буенча белем алганнан соң алты ай узганнан соң һәм күбрәк вакыт эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен кимендә 10 процент тәэмин итү;

һөнәри уку узганнан соң өч ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен кимендә 20 процент тәэмин итү;

һөнәри уку узганнан соң алты ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен кимендә 35 процент тәэмин итү;

һөнәри уку узганнан соң алты ай узганнан соң һәм күбрәк вакыт эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен кимендә 15 процент тәэмин итү;

өстәмә һөнәри программаларны (квалификация күтәрү программалары һәм һөнәри яңадан әзерләү программалары) үзләштергәннән соң өч ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен кимендә 35 процент тәэмин итү;

өстәмә һөнәри программаларны (квалификация күтәрү программалары һәм һөнәри яңадан әзерләү программалары) үзләштергәннән соң алты ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен кимендә  50 процент тәэмин итү;

гары белем алганнан соң укуын дәвам иткән яшь инвалидлар арасыннан укып бетерүчеләр өлешен кимендә  0,5 процент тәэмин итү;

урта һөнәри белем алганнан соң укуын дәвам иткән яшь инвалидлар арасыннан укып бетерүчеләр өлешен кимендә  15 процент тәэмин итү;

халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендәге чаралар кысаларында укыган хезмәткәрләр арасыннан эшкә урнашкан хезмәткәрләр өлешен кимендә 90 процент тәэмин итү.

Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары – 2014 – 2020 еллар.

Эш белән тәэмин итү ярдәмче программасы бер этапта тормышка ашырылачак, бу каралган чараларның өзлексезлеген һәм күчемлелеген тәэмин итә.

Индикаторларның фаразланган мәгънәләрен Эш белән тәэмин итү ярдәмче программасы максатлары, бурычлары һәм чаралары күзлегеннән чыгып тулы тасвирламасы аңарга кушымтада китерелә.»;

Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программаның III бүлегендә:

беренче абзацта «9 928 138,48» саннарын «9 936 465,28» саннарына алыштырырга;

өченче абзацта «4 888 689,68» саннарын «4 897 016,48» саннарына алыштырырга;

Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программа 1 нче кушымтада:

9 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «9. | Урта һөнәри һәм югары белем алган инвалидларны, шулай ук Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларында һөнәри әзерлек узган коррекцион мәктәпләрне тәмамлаучыларны эшкә урнаштыруны һәм эш урынында беркетүне мониторинглау | хисап | ел саен | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | югары белем бирүче мәгариф программалары буенча белем алганнан соң өч ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлешен*, процент;<br><br>урта һөнәри белем бирүче мәгариф программалары буенча белем алганнан соң өч ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлеше*, процент; | кимендә 55 процент<br><br>кимендә 40 процент |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | югары белем бирүче мәгариф программалары буенча белем алганнан соң алты ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлеше*, процент; | кимендә 65 процент |
| | | | | | урта һөнәри белем бирүче мәгариф программалары буенча белем алганнан соң алты ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлеше*, процент; | кимендә 50 процент |
| | | | | | югары белем бирүче мәгариф программалары буенча белем алганнан соң алты ай узганнан соң һәм күбрәк вакыт эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлеше*, процент; | кимендә 15 процент |
| | | | | | урта һөнәри белем бирүче мәгариф программалары буенча белем алганнан соң алты ай узганнан соң һәм күбрәк вакыт эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлеше*, процент; | кимендә 10 процент |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | югары белем алганнан соң укуын дәвам иткән яшь инвалидлар арасыннан укып бетерүчеләр өлеше*, процент;<br><br>урта һөнәри белем алганнан соң укуын дәвам иткән яшь инвалидлар арасыннан укып бетерүчеләр өлеше*, процент | кимендә 0,5 процент<br><br>кимендә 15 процент»; |

21 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «21. | Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнарының халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре юлламасы буенча һөнәри уку узган һәм һөнәри белем алган, шул исәптән үзләренең эшкә урнашуына озатып барулы булышлык алган инвалидларны эшкә урнаштыруны һәм эш урынында беркетүне мониторинглау | хисап | ел саен | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, дәүләт казна учреждениеләре – Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре | һөнәри уку узганнан соң өч ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлеше*, процент;<br><br>һөнәри уку узганнан соң алты ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлеше тәэмин*, процент;<br><br>һөнәри уку узганнан соң алты ай узганнан соң һәм күбрәк вакыт эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлеше*, процент;<br><br>өстәмә һөнәри программаларны (квалификация күтәрү | кимендә 20 процент<br><br>кимендә 35 процент<br><br>кимендә 15 процент<br><br>кимендә 35 процент |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | программалары һәм һөнәри яңа-дан әзерләү программалары) үзләштергәннән соң өч ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлеше*, процент;<br><br>өстәмә һөнәри программаларны (квалификация күтәрү программалары һәм һөнәри яңадан әзерләү программалары) үзләштергәннән соң алты ай эчендә эш тапкан яшь инвалидлар өлеше*, процент | <br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>кимендә 50 процент»; |

1 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«*Күрсәткечләрнең мәгънәләре Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү чаралары кысаларында эшкә урнашканда яшь инвалидларны озата бару буенча үрнәк программаны раслау турында» 2017 ел, 23 август, 625 нче боерыгы нигезендә исәпләнә;

Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программага 2 нче кушымтада:

1.10 пунктта 18 графадагы «369 022,3» саннарын «377 349,1» саннарына алыштырырга;

«Ярдәмче программа буенча барлыгы, шул исәптән:» пунктында 18 графадагы «1 374 122,6» саннарын «1 382 449,4» саннарына алыштырырга;

«Татарстан Республикасы бюджеты акчасы» пунктында 18 графадагы «732 335,1» саннарын «740 661,9» саннарына алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин